| ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ<br>ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>ЗЕЛЕНОДОЛЬСК<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ<br>БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |
|---|---|---|
| **ПОСТАНОВЛЕНИЕ**<br>**05.04.2021** | Зеленодольск<br>шәһәре | **КАРАР**<br>**№ 732** |

Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының 2018 елның 28 июнендә кабул ителгән 1366 нчы номерлы «Зеленодольск муниципаль районы муниципаль мәдәният учреждениеләре хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турында» карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының дәүләт мәдәният учреждениеләре хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турында» 2018 елның 31 маенда 413 нче карарына үзгәрешләр кертү турында 2020 елның 30 декабрендә кабул ителгән 1245 нче карарын үтәү йөзеннән, Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының «Зеленодольск муниципаль районы муниципаль мәдәният учреждениеләре хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү шартлары турында» 2018 елның 28 июнендәге 1366 номерлы карарына (25.07.2018 елгы 1502 номерлы карары белән кертелгән үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1 Зеленодольск муниципаль районының муниципаль китапханәләренең, музейларның, музей тибындагы башка учреждениеләрнең һәм мәдәни-ял учреждениеләренең мәдәният, сәнгать һәм кинематография хезмәткәрләре вазыйфаларының һөнәри квалификация төркемнәре хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турында нигезләмәне яңа редакциядә расларга (кушымта 1);

1.2 Зеленодольск муниципаль районы муниципаль мәдәният учреждениеләренең фәнни тикшеренүләр һәм эшләнмәләр өлкәсе хезмәткәрләре вазыйфаларының һөнәри квалификация төркемнәре хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү шартлары турында нигезләмәне расларга( 3 нче кушымта).

2. Зеленодольск муниципаль районының «Зеленодольск муниципаль районы муниципаль мәдәният учреждениеләре хезмәткәрләренең хезмәтенә түләү шартлары турында» 2018 елның 28 июнендәге 1366 номерлы Башкарма комитет карарын

Зеленодольск муниципаль районының муниципаль китапханәләренең, музейларның, музей тибындагы башка учреждениеләрнең һәм мәдәни-ял учреждениеләренең мәдәният, сәнгать һәм кинематография хезмәткәрләре вазыйфаларының һөнәри квалификация төркемнәре хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турында нигезләмә өлешендә һәм Зеленодольск муниципаль районы муниципаль мәдәният учреждениеләренең фәнни тикшеренүләр һәм эшләнмәләр өлкәсе хезмәткәрләре вазыйфаларының һөнәри квалификация төркемнәре хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү шартлары турында нигезләмәне үз көчен югалткан дип санарга

3 Учреждение җитәкчеләренә үзләренең локаль норматив актларын әлеге карарга туры китерергә.

4. Зеленодольск муниципаль районы Советы Аппаратының җәмәгатьчелек һәм массакүләм мәгълүмат чаралары белән элемтә бүлеге начальнигы Р. З. Хажиевка әлеге карарны Интернет челтәрендәге Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составында Зеленодольск муниципаль районының мәгълүмати сайтында (http://zelenodolsk.tatarstan.ru) урнаштырырга.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Җитәкче И. Р. Ганиев

Башкарма комитет карарына кушымта
Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты
05.04.2021 №732

# ЗЕЛЕНОДОЛЬСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ МУНИЦИПАЛЬ МӘДӘНИЯТ УЧРЕЖДЕНИЕЛӘРЕ ХЕЗМӘТКӘРЛӘРЕНӘ ХЕЗМӘТ ӨЧЕН ТҮЛӘҮ ШАРТЛАРЫ ТУРЫНДА

## Зеленодольск муниципаль районының муниципаль китапханәләренең, музейларның, музей тибындагы башка учреждениеләрнең һәм мәдәни-ял итү учреждениеләренең мәдәният, сәнгать һәм кинематография хезмәткәрләре вазыйфаларының һөнәри квалификация төркемнәре хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турында НИГЕЗЛӘМӘ

### I. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Әлеге Нигезләмә Зеленодольск муниципаль районының муниципаль китапханәләренең,музейларның, музей тибындагы башка учреждениеләрнең һәм мәдәни-ял итү учреждениеләренең мәдәният, сәнгать һәм кинематография хезмәткәрләре вазыйфаларының һөнәри квалификация төркемнәре хезмәткәрләрнең (алга таба-Нигезләмә)окладларын формалаштыру тәртибен, компенсация һәм кызыксындыру сыйфатындагы түләүләр шартларын һәм күләмен, шулай ук аларны билгеләү критерийларын билгели.

1.2. Әлеге Нигезләмәдә түбәндәге төшенчәләр һәм билгеләмәләр кулланыла:

хезмәткә түләү системасы- төп окладлар, хезмәт хакының төп ставкалары, вазифаи окладлар күләмнәрен, шулай ук федераль законнар һәм Россия Федерациясенең һәм Татарстан Республикасының башка норматив хокукый актлары нигезендә билгеләнгән компенсация һәм кызыксындыру сыйфатындагы түләүләр күләмен дә кертеп, учреждениеләр хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү шартларын һәм күләмнәрен билгели торган нормалар җыелмасы;

төп оклад, хезмәт хакының төп ставкасы –эшче һөнәре яки җитәкче, белгеч, техник башкаручы вазифасы буенча һөнәри эшчәнлекне башкаручы хезмәткәренең компенсация һәм кызыксындыру сыйфатындагы түләүләрне исәпкә алынмаган минималь оклады

вазыйфаи оклад - чынлыкта эшләгән вакыт өчен бер календарь айга билгеле бер катлаулылыктагы хезмәт (вазифаи) бурычларын үтәгән өчен хезмәткәр хезмәтенә түләүнең компенсация һәм кызыксындыру сыйфатындагы түләүләрне исәпкә алынмаган, теркәлгән күләме;

хезмәт хакы (хезмәткәрнең хезмәтенә түләү) - хезмәткәрнең квалификациясенә, башкарыла торган эшнең катлаулылыгына, күләменә, сыйфатына һәм шартларына карап, хезмәт өчен түләү, шулай ук компенсация һәм кызыксындыру сыйфатындагы түләүләр;

компенсация сыйфатындагы түләүләр - нормаль булмаган шартлардагы эш өчен түләүләрне дә кертеп, компенсация сыйфатында өстәмәләр, өстәмә түләү һәм компенсация сыйфатындагы башка түләүләр;

кызыксындыру сыйфатындагы түләүләр – кызыксындыру сыйфатында өстәмәләр һәм өстәмә түләүләр, премияләр һәм башка бәүләкләү түләүләре.

1.3. Зеленодольск муниципаль районының муниципаль китапханәләренең, музейларның, музей тибындагы башка учреждениеләрнең һәм мәдәни-ял итү учреждениеләренең мәдәният, сәнгать һәм кинематография хезмәткәрләре вазыйфаларының һөнәри квалификация төркемнәре хезмәткәрләрнең (алга таба – мәдәният хезмәткәрләре) хезмәт хакы (хезмәте өчен түләү) түбәндәгеләрдән чыгып билгеләнә:

окладтан (вазыйфаи окладларыннан), хезмәт хакы ставкаларыннан;

компенсация сыйфатындагы түләүләрдән;

кызыксындыру максатындагы түләүләрдән

1.4. Юнәлеш буенча эш стажы артуга, белем алуга яисә белем алу турындагы документларны торгызуга, квалификация категориясе бирелүгә, дәүләт бүләге бирелүгә, тармак буенча аерымлык билгеләре белән бүләкләнүгә, еллык яисә башка ялда булу вакытында, аның вакытлыча хезмәткә яраксызлык чорында, шулай ук аның уртача хезмәт хакы сакланып кала торган башка чорлар булуга бәйле рәвештә хезмәтенә түләү күләме үзгәрүгә хокукы барлыкка килгәндә, аның хезмәтенә түләү күләме күрсәтелгән чорлар тәмамланганнан соң үзгәртелә.

## II. Мәдәният хезмәткәрләренең хезмәт хакын түләү буенча төп окладларын билгеләү

| Вазыйфаның исеме | Аена төп оклад күләме, сумнарда | | |
|---|---|---|---|
| | Төп гомуми белем, урта гомуми белем | Квалификацияле эшчеләр, хезмәткәрләр әзерләү программалары буенча урта һөнәри белем, урта буын белгечләрен әзерләү программалары буенча урта һөнәри белем, тулы булмаган югары белем | Аттестацияне уңышлы үткән затка «бакалавр», «магистр» яки «дипломлы белгеч » квалификацияләрен бирү белән раслана торган югары һөнәри белем |
| 1 | 2 | 3 | 4 |
| «Техник башкаручылар һәм ярдәмче состав артистлары вазыйфаларының» һөнәри квалификация төркеме | | | |
| Билет контролеры | 9 489 | | |
| Музей караучы | 9 489 | 12 146 | |
| «Урта буын мәдәният, сәнгать һәм кинематография хезмәткәрләре вазыйфалары» һөнәри квалификация төркеме | | | |
| Билет кассалары мөдире | 9 500 | 12 350 | |
| Аттракционда контролер-утыртучы | 9 500 | 12 350 | 14 915 |
| Экскурсияләр оештыручы | 9 500 | 12 350 | 14 915 |
| Костюмер мөдире | 9 500 | 12 350 | |
| Ассистентлар: режиссер, дирижер, балетмейстер, хормейстер | 9 500 | 12 350 | 14 915 |
| Оркестр (ансамбль), кинотеатрларга, рестораннарга, кафеларга һәм бию мәйданчыкларына хезмәт күрсәтүче оркестр артисты | 9 500 | 12 350 | 14 915 |

| 1 | 2 | 3 | 4 |
|---|---|---|---|
| Түгәрәк, һәвәскәрләр берләшмәсе, кызыксыну клубы җитәкчесе | 9 500 | 12 350 | 14 915 |
| Аккомпаниатор | 9 500 | 12 350 | 14 915 |
| Мәдәни оештыручы | 9 500 | 12 350 | 14 915 |
| Бию кичәсе җитәкчесе | 9 500 | 12 350 | 14 915 |
| Дискотекалар алып баручы | 9 500 | 12 350 | 14 915 |
| Режиссер ярдәмчесе | 9 500 | 12 350 | 14 915 |
| Фильмофондны ремонтлау һәм реставрацияләү участогы мастеры | 9 500 | 12 350 | 14 915 |
| «Әйдәп баручы буын мәдәният, сәнгать һәм кинематография хезмәткәрләренең вазыйфалары» һөнәри квалификация төркеме | | | |
| Китапханәче | 9 530 | 12 484 | 15 343 |
| Аккомпаниатор-концертмейстер | 9 530 | 12 484 | 15 343 |
| Тавыш операторы | 9 530 | 12 484 | 15 343 |
| Лектор (экскурсовод) | 9 530 | 12 484 | 15 343 |
| Китапханә, музей һәм башка шундый ук учреждениеләр һәм оешмалар мөхәррире | 9 530 | 12 484 | 15 343 |
| Администратор | 9 530 | 12 484 | 15 343 |
| Китапханә, музей һәм башка шундый ук учреждение һәм оешмалар методисты | 9 530 | 12 484 | 15 343 |
| Библиограф | 9 530 | 12 484 | 15 343 |
| Экспозиция һәм күргәзмә бүлеге белгече | 9 530 | 12 484 | 15 343 |
| Рәссам-декоратор | 9 530 | 12 484 | 15 343 |
| Рәссам-конструктор | 9 530 | 12 484 | 15 343 |
| Рәссам-сынчы | 9 530 | 12 484 | 15 343 |
| Рәссам-реставратор | 9 530 | 12 484 | 15 343 |
| Рәссам-фотограф | 9530 | 12 484 | 15 343 |

| 1 | 2 | 3 | 4 |
|---|---|---|---|
| Рәссам-бизәүче | 9 530 | 12 484 | 15 343 |
| Ут буенча рәссам | 9 530 | 12 484 | 15 343 |
| Әйдәп баручы китапханәче | 9 530 | 12 484 | 15 343 |
| Әйдәп баручы библиограф | 9 530 | 12 484 | 15 343 |
| Исәп-саклау документлары буенча белгеч | 9 530 | 12 484 | 15 343 |
| Клуб учреждениесе, халык иҗаты фәнни-методик үзәге, халык иҗаты йорты, халык мәдәнияты (мәдәният һәм ял итү) үзәге һәм башка шундый ук учреждениеләр һәм оешмалар мөхәррире | 9 530 | 12 484 | 15 343 |
| Клуб эше методикасы буенча белгеч | 9 530 | 12 484 | 15 343 |
| Кинопрограммалар төзү буенча методист | 9 530 | 12 484 | 15 343 |
| Администраторы (өлкән администраторы) | 9 530 | 12 484 | 15 343 |
| Клуб учреждениесе, халык иҗаты фәнни-методик үзәге, халык иҗаты йорты, халык мәдәнияты (мәдәният һәм ял итү) үзәге һәм башка шундый ук учреждениеләр һәм оешмалар методисты | 9 530 | 12 484 | 15 343 |
| Кинооператор | 9 530 | 12 484 | 15 343 |
| Репертуар буенча мөхәррир | 9 530 | 12 484 | 15 343 |
| Фольклор белгече | 9 530 | 12 484 | 15 343 |
| Аттракцион мөдире | 9 530 | 12 484 | 15 343 |
| Артист-вокалчы (солист) | 9 530 | 12 484 | 15 343 |
| Оркестр артисты | 9 530 | 12 484 | 15 343 |
| Мөхәррир (музыкаль мөхәррир) | 9 530 | 12 484 | 15 343 |
| Иҗат жанрлары буенча белгеч | 9 530 | 12 484 | 15 343 |
| Рәссам-куючы | 9 530 | 12 484 | 15 343 |
| Китапханә, музей һәм башка шундый ук | 9 530 | 12 484 | 15 343 |

| 1 | 2 | 3 | 4 |
|---|---|---|---|
| учреждениеләр һәм оешмаларның әйдәп баручы методисты | | | |
| Баш китапханәче | 9 530 | 12 484 | 15 343 |
| Баш библиограф | 9 530 | 12 484 | 15 343 |
| Фондларны саклаучы | 9 530 | 12 484 | 15 343 |
| «Мәдәният, сәнгать һәм кинематография учреждениеләренең җитәкче составы вазыйфалар » һөнәри квалификация төркеме | | | |
| Музей бүлеге (секторы) мөдире | 9 550 | 12 797 | 15 662 |
| Китапханәнең бүлек (секторы) мөдире | 9 550 | 12 797 | 15 662 |
| Мәдәният йорты (сарае), мәдәният һәм ял паркы, халык иҗаты фәнни-методик үзәге, халык иҗаты йорты, халык мәдәнияте (мәдәният һәм ял итү) үзәге һәм башка шундый ук учреждение һәм оешмалар бүлеге (секторы) мөдире | 9 550 | 12 797 | 15 662 |
| Музейның күчмә күргәзмә мөдире | 9 550 | 12 797 | 15 662 |
| Фондларның баш саклаучысы | 9 550 | 12 797 | 15 662 |
| Сәнгать-бизәү остаханәсе мөдире | 9 550 | 12 797 | 15 662 |
| Зоопарк бүлеге (секторы) мөдире | 9 550 | 12 797 | 15 662 |
| Зоопаркның ветеринария лабораториясе мөдире | 9 550 | 12 797 | 15 662 |
| Режиссер (дирижер, балетмейстер, хормейстер) | 9 550 | 12 797 | 15 662 |
| Балетмейстер-куючы | 9 550 | 12 797 | 15 662 |
| Сәнгать житәкчесе | 9 550 | 12 797 | 15 662 |
| Реставрация остаханәсе мөдире | 9 550 | 12 797 | 15 662 |
| Тавыш режиссеры | 9 550 | 12 797 | 15 662 |
| Кино-һәм видеофильмнарны прокатка | 9 550 | 12 797 | 15 662 |

| 1 | 2 | 3 | 4 |
|---|---|---|---|
| бирү бүлеге мөдире | | | |
| Клуб берләшмәсе, һәвәскәрләр берләшмәсе, студия, үзешчән сәнгать коллективы, кызыксыну клубы җитәкчесе | 9 550 | 12 797 | 15 662 |
| Режиссер-куючы | 9 550 | 12 797 | 15 662 |
| Массакүләм тамашалар режиссеры | 9 550 | 12 797 | 15 662 |
| Аттракцион техниканы эксплуатацияләү бүлеге мөдире | 9 550 | 12 797 | 15 662 |
| Баш рәссам | 9 550 | 12 797 | 15 662 |

| Һөнәри стандарт нигезендә вазыйфаның исеме | Аена төп оклад күләме, сумнарда | |
|---|---|---|
| | Урта буын белгечләрен әзерләү программалары буенча урта һөнәри белем, тулы булмаган югары белем | Аттестацияне уңышлы үткән затка «бакалавр», «магистр» яки «дипломлы белгеч » квалификацияләрен бирү белән расланган югары һөнәри белем |
| Музей предметларын саклаучы | | 15 343 |
| Музей предметларын исәпкә алу буенча белгеч | 12 484 | 15 343 |
| Экскурсовод | 12 484 | 15 343 |
| Тәрҗемәче | 12 484 | 15 343 |
| Баш саклаучы | | 15 662 |
| Музейны исәпкә алу бүлеге (секторы) мөдире | | 15 662 |

Өстәмә рәвештә «Музейның бүлек (сектор) мөдире», «Музейны исәпкә алу бүлеге (секторы) мөдире», «Китапханә (бүлек) мөдире», «Мәдәният йорты (сектор), мәдәният һәм ял паркы, халык иҗаты фәнни-методик үзәге, халык иҗаты йорты, халык мәдәнияте (ял итү) үзәге һәм башка шундый учреждениеләр һәм оешмалар бүлеге мөдире», «Зоопаркның бүлек (секторы)

мөдире», «Кино - һәм видеофильмнарны прокатка бирү бүлеге (пункт) мөдире» һәм «Сәнгать җитәкчесе» вазыйфалары буенча төп окладына –. 1,1коэффициенты кулланыла.

## III. Мәдәният хезмәткәрләренең вазыйфаи окладларын формалаштыру тәртибе

3.1. Мәдәният хезмәткәрләренең вазыйфаи оклады түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$O_d = O_b \times S,$$

биредә:
$O_d$ – мәдәният хезмәткәрләренең вазыйфаи окладлары;
$O_b$ – мәдәният хезмәткәрләренең әлеге Нигезләмәнең 2 бүлеге нигезендә кабул ителә торган төп оклады күләме;
$S$ – мәдәният хезмәткәре тарафыннан башкарыла торган ставкаларның фактгагы саны.
3.2. Әгәр биләгән вазыйфа югары белем таләп итмәсә - бакалавриат яки специалитет яки магистратура, урта буын белгечләрен әзерләү программалары буенча урта һөнәри белем бирү,югары белемле затлар - бакалавриат яки специалитет яки магистратура, урта буын белгечләрен әзерләү программалары буенча урта һөнәри белем, квалификацияле эшчеләр, хезмәткәрләр әзерләү программалары буенча урта һөнәри белем белән шөгыльләнүче вазыйфалар буенча урта гомуми белемгә туры килә торган хезмәт өчен түләү разряды билгеләнә.
3.3. Вазыйфага квалификация таләпләре төрле белем дәрәҗәләрен күздә тоткан очракта, фактта булган белем дәрәҗәсенә туры килә торган хезмәт өчен түләү разряды билгеләнә.
3.4. Белем дәрәҗәсе үзгәргән очракта, мәдәният хезмәткәренең окладын тиешле белем алу турында дәүләт үрнәгендәге документны биргәннән соң корректировкага алынырга тиеш.

## IV. Кызыксындыру сыйфатындагы түләүләр

4.1. Кызыксындыру сыйфатындагы түләүләргә хезмәткәрне сыйфатлы хезмәт нәтиҗәләренә стимуллаштыруга, шулай ук башкарылган эш өчен бүләкләүгә юнәлдерелгән түләүләр керә.
4.2. Кызыксындыру сыйфатындагы түләүләр түбәндәгеләрне үз эченә ала:
эшчәнлек үзенчәлеге өчен түләүләрне;
мактаулы исемнәр, дәүләт бүләкләре булган өчен түләүне;
квалификация категориясе өчен түләүләрне;
юнәлеш буенча эш стажы өчен түләүләрне;
башкарылган эшләрнең сыйфаты өчен премиаль түләүләрне;
премияләр һәм башка бүләкләү түләүләрен.
4.3. Эшчәнлек үзенчәлеге өчен түләүләр мәдәният, сәнгать һәм кинематография профессиональ квалификация төркемнәре хезмәткәрләренә урта,әйдәп баручы буын һәм аерым учреждениеләрдә җитәкче состав вазыйфаларына бирелә һәм түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$B_{sd} = O_d \times D_{sd},$$

биредә:

$B_{sd}$ – эшчәнлек үзенчәлеге өчен түләүләр;
$O_d$ – мәдәният хезмәткәрләренең вазыйфаи окладлары;
$D_{sd}$ – эшчәнлек үзенчәлеге өчен өстәмә түләү күләме.
Эшчәнлек үзенчәлеге өчен өстәмә түләүләр күләме 1нче таблицада күрсәтелгән
4.4. Әлеге учреждениедә, бүлекчәдә һәм вазыйфада конкрет эш шартларын исәпкә алып, эшчәнлек үзенчәлеге өчен өстәмәләр билгеләнә торган мәдәният хезмәткәрләре вазыйфалары исемлеге һәр учреждение тарафыннан сайлап алынган профсоюз органы (яки вәкаләтле башка орган) белән килешү буенча раслана.

1 нче таблица

Эшчәнлек үзенчәлеге өчен тәкъдим ителә торган өстәмә түләүләр күләме

| № т/б | Эшчәнлек үзенчәлеге өчен өстәмә түләүләрне билгеләү нигезләре | Һөнәри квалификация төркеме исеме | Өстәмә түләү күләме, процентларда |
|---|---|---|---|
| 1. | Физик үсеш кимчелекләре булган затларга хезмәт күрсәтү (сукырлар, чукраклар) | урта буын мәдәният, сәнгать һәм кинематография хезмәткәрләре вазыйфалары | 5 |
| | | әйдәп баручы буын мәдәният, сәнгать һәм кинематография хезмәткәрләре вазыйфалары | 5 |
| 2. | Милли статуска ия булган мәдәният, сәнгать һәм кинематография учреждениеләрендә эш | әйдәп баручы буын мәдәният, сәнгать һәм кинематография хезмәткәрләре вазыйфалары | 30 |
| | | мәдәният, сәнгать һәм кинематография учреждениеләренең җитәкче составы вазыйфалары | 30 |
| 3. | Гамәли эштә чит телне куллану | әйдәп баручы буын мәдәният, сәнгать һәм кинематография хезмәткәрләре вазыйфалары | 5 |
| | | мәдәният, сәнгать һәм кинематография учреждениеләренең җитәкче составы вазыйфалары | 5 |
| 4. | Милли статуска ия булган мәдәният учреждениеләрендә практик эштә ике дәүләт телен куллану * | әйдәп баручы буын мәдәният, сәнгать һәм кинематография хезмәткәрләре вазыйфалары | 10 |
| | | мәдәният, сәнгать һәм кинематография учреждениеләренең җитәкче | 10 |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | составы вазыйфалары | |

* Милли статуска ия учреждениеләргә «Татарстан Республикасы Милли китапханәсе» дәүләт бюджет мәдәният учреждениесе, «Татарстан Республикасы Милли музее»дәүләт бюджет мәдәният учреждениесе керә.

4.5. Мактаулы исемнәр, дәүләт бүләкләре булган өчен түләүләр мәдәният, сәнгать һәм кинематография хезмәткәрләре вазыйфаларының һөнәри квалификация төркемнәренә керүче хезмәткәрләргә бирелә һәм түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$B_{pz} = O_d \times D_{pz},$$

биредә:

$B_{pz}$ - мактаулы исемнәргә, дәүләт бүләкләренә ия булган өчен түләү;

$O_d$ – мәдәният хезмәткәрләренең вазыйфаи окладлары;

$D_{pz}$ - мактаулы исемнәр, дәүләт бүләкләре булган өчен өстәмә түләү күләме.

4.6. Совет Социалистик Республикалары Союзы составында автоном республикаларның мактаулы исемнәре,Татарстан Республикасының мактаулы исемнәре, дәүләт бүләкләре өчен өстәмә түләү күләме 8 процент тәшкил итә.

Россия Федерациясе, Совет Социалистик Республикалар Союзы, Совет Социалистик Республикалар Союзы составындагы союздаш республикаларның мактаулы исемнәре булган өчен өстәмә түләү күләме 10 процент тәшкил итә.

Кызыксындыру сыйфатындагы тиешле түләүләр түләнә торган Россия Федерациясе, Совет Социалистик Республикалар Союзы, Совет Социалистик Республикалар Союзы составындагы союздаш республикаларның мактаулы исемнәре, дәүләт бүләкләре исемлеге әлеге кушымтаның Нигезләмәсенә китерелгән.

4.7. Мактаулы исемнәр, дәүләт бүләкләре булган өчен түләү күләмен билгеләү мактаулы исем, дәүләт бүләге бирелгән көннән башкарыла. Ике һәм аннан да күбрәк мактаулы исем, ике һәм аннан да күбрәк дәүләт бүләкләре, мактаулы исемнәр, дәүләт бүләкләре булган өчен түләү мактаулы исемнәрнең берсе, хезмәткәрнең сайлавы буенча дәүләт бүләкләренең берсе буенча билгеләнә.

4.8. Квалификация категориясе өчен түләүләр тариф-квалификация характеристикалары нигезендә һөнәри-квалификация төркемнәре киселешендә аттестация нәтиҗәләре буенча квалификация категорияләрен бирүне күздә тотучы белгечлекләр буенча эшләүче хезмәткәрләргә бирелә. Квалификация категориясе өчен түләүләр түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$B_{kk} = O_d \times D_{kk},$$

биредә:

$B_{kk}$ – квалификация категориясе өчен түләү;

$O_d$ – мәдәният хезмәткәрләренең вазыйфаи окладлары;

$D_{kk}$ – квалификация категориясе өчен өстәмә түләүләр күләме.

Квалификация категориясе өчен өстәмәләр түләүләр күләме 2 нче таблицада китерелгән.

Квалификация категориясе өчен түләүләрне үзгәртү (билгеләү) аттестация

комиссиясен төзегән орган (учреждение) боерыгындагы дата нигезендә башкарыла.

2 нче таблица

Квалификация категориясе өчен өстәмә түләүләр күләме

| Квалификация категориясе | Өстәмә түләү күләме, процентларда |
|---|---|
| Әйдәп баручы буын мәдәният хезмәткәрләре вазыйфаларының һөнәри-квалификация төркеме | |
| 2 квалификация категориясе | 2 |
| 1 квалификация категориясе | 4 |
| Югары квалификация категориясе, шулай ук «баш» исеме белән алмаштырылган вазыйфалар | 6 |

4.9. Юнәлеш буенча эш стажы өчен түләүләр һөнәри квалификация төркемнәренең юнәлеше буенча эшнең дәвамлылыгына карап билгеләнә һәм түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$B_s = O_d \times D_s,$$

биредә:

$B_s$ – юнәлеш буенча эш стажы өчен түләү;

$O_d$ – мәдәният хезмәткәрләренең вазыйфаи окладлары;

$D_s$ - юнәлеш буенча эш стажы өчен өстәмә түләү күләме.

Юнәлеш буенча эш стажына өстәмә түләүләр күләме 3 таблицада китерелгән.

3 нче таблица

Юнәлеш буенча эш стажы өчен өстәмә түләүләр күләме

| Һөнәри квалификация төркеменең исеме | Стаж буенча төркем | Өстәмә түләү күләме, процентларда |
|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 |
| Урта буын мәдәният, сәнгать һәм кинематография хезмәткәрләре вазыйфалары | 3 елдан 10 елга кадәр | 12 |
| | 10 елдан алып 15 елга кадәр | 14 |
| | 15 елдан 20 елга кадәр | 16 |
| | 20 елдан 25 елга кадәр | 18 |
| | 25 елдан артык | 22 |
| Әйдәп баручы буын мәдәният, сәнгать | 3 елдан 10 елга | 12 |

| 1 | 2 | 3 |
|---|---|---|
| һәм кинематография хезмәткәрләре вазыйфалары | кадәр | |
| | 10 елдан алып 15 елга кадәр | 14 |
| | 15 елдан 20 елга кадәр | 16 |
| | 20 елдан 25 елга кадәр | 18 |
| | 25 елдан артык | 22 |
| Мәдәният, сәнгать һәм кинематография учреждениеләренең җитәкче составы вазыйфалары | 3 елдан 10 елга кадәр | 12 |
| | 10 елдан алып 15 елга кадәр | 14 |
| | 15 елдан 20 елга кадәр | 16 |
| | 20 елдан 25 елга кадәр | 18 |
| | 25 елдан артык | 22 |

4.10. Эш вакыты вазыйфасы (белгечлеге) буенча эш стажына кертелгән вазыйфалар (һөнәрләр) исемлеге Татарстан Республикасы мәдәният министры боерыгы белән раслана.

4.11. Эш стажы үзгәргәндә юнәлеш буенча эш стажы өчен түләүләр күләмен билгеләү (үзгәртү) юнәлеш буенча эш стажы өчен түләүләр күләмен арттыру хокукын бирә торган стажга ирешкән көннән алып (әгәр стажны раслый торган документлар учреждениедә булса) яисә стажны раслый торган кирәкле документ бирелгән көннән алып башкарыла.

4.12. Башкарыла торган эшләрнең сыйфаты өчен премиаль түләүләр билгеле бер чор (ай, квартал, ел) хезмәт нәтиҗәләре буенча мәдәният хезмәткәрләренең һөнәри квалификация төркемнәре хезмәткәрләренә билгеләнә. Башкарыла торган эшләрнең сыйфаты өчен премиаль түләүләр күләменә йогынты ясый торган төп критерий-Татарстан Республикасы мәдәният министры боерыгы белән расланган мәдәният хезмәткәрләре эшчәнлегенең нәтиҗәлелеген бәяләү критерийларының иң чик күрсәткечләренә ирешү.

4.13. Мәдәният учреждениеләре хезмәткәрләре эшчәнлегенең нәтиҗәлелеген бәяләү критерийлары аның җитәкчесе тарафыннан раслана. Мәдәният хезмәткәрләре эшчәнлегенең нәтиҗәлелеген бәяләү критерийларының конкрет әһәмиятләре һәм түләүләрне гамәлгә ашыру шартлары учреждение алдында торган бурычлардан чыгып ел саен билгеләнә.

4.14. Башкарылган эшләрнең сыйфаты өчен премиаль түләүләрнең күләме, тәртибе һәм шартлары учреждениенең локаль норматив хокукый актлары һәм күмәк шартнамәләре белән билгеләнә.

4.15. Башкарыла торган эшләрнең сыйфаты өчен премиаль түләүләр һөнәри квалификация төркемнәре буенча билгеләнә һәм түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$B_k = O_d \times D_k,$$

биредә:
$B_k$ – башкарылган эшләрнең сыйфаты өчен премиаль түләүләр;
$O_d$ – мәдәният хезмәткәрләренең вазыйфаи окладлары;
$D_s$ - башкарыла торган эшләрнең сыйфаты өчен өстәмә түләүнең чик күләме.
Башкарыла торган эшләрнең сыйфаты өчен өстәмә түләүләрнең чик күләме 4 нче таблицада китерелгән.

4 нче таблица

Башкарыла торган эшләрнең сыйфаты өчен өстәмә түләүләрнең чик күләмнәре

| Һөнәри квалификация төркеме исеме | Өстәмә түләү, процентлар күләме |
|---|---|
| 1 | 2 |
| Техник башкаручылар һәм ярдәмче состав артистлары вазыйфалары | 14 |
| Урта буын мәдәният, сәнгать һәм кинематография хезмәткәрләре вазыйфалары | 28 |
| Әйдәп баручы буын мәдәният, сәнгать һәм кинематография хезмәткәрләре вазыйфалары | 38 |
| Мәдәният, сәнгать һәм кинематография учреждениеләренең житәкче составы вазыйфалары | 48 |

4.16. Премия һәм башка кызыксындыру түләүләре юбилей даталары, аерымлык билгеләре, рәхмәт хатлары, грамоталар, дәүләт бүләкләре алу һәм оешманың локаль актлары һәм күмәк шартнамәләр белән билгеләнгән башка нигезләр буенча хезмәткәрләргә бер тапкыр бирелә торган вакыт (ай, квартал, ел) чорында билгеләнә.
4.17. Премиаль һәм башка бүләкләү түләүләре бер үк вакытта, шул исәптән Зеленодольск муниципаль районы мәдәният учреждениеләре хезмәткәрләре эшчәнлегенең нәтиҗәлелеген арттыру максатларында, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Чаралар планы турында («юл картасы») «Социаль өлкә тармакларында мәдәният өлкәсенең нәтиҗәлелеген күтәрүгә юнәлдерелгән үзгәрешләр» 2013 елның 04 апрелендәге 227 номерлы карары белән расланган, «Социаль өлкә тармакларында мәдәният өлкәсенең нәтиҗәлелеген күтәрүгә юнәлдерелгән үзгәрешләр» чаралар планын («юл картасын») үтәгәндә билгеләнә ала.
4.18. Премия һәм башка кызыксындыру түләүләренең күләме, тәртибе һәм шартлары учреждениенең локаль норматив хокукый актлары һәм күмәк шартнамәләре белән билгеләнә.

## V. Учреждение җитәкчесе, учреждение җитәкчесе урынбасары, баш хисапчының хезмәт хакын билгеләү тәртибе

5.1. Учреждение җитәкчеләренең, учреждение җитәкчеләре урынбасарларының һәм баш хисапчыларның хезмәт хакы вазыйфаи окладлардан һәм компенсация һәм кызыксындыру сыйфатындагы түләүләрдән тора.
5.2. Мәдәният учреждениесе җитәкчесе оклады, хезмәткә түләү төркеменә карап, елына бер тапкыр мәдәният учреждениесен гамәлгә куючы тарафыннан билгеләнә. Мәдәният учреждениесе җитәкчесенең хезмәт хакы буенча төркем мәдәният учреждениесе хезмәткәрләренең штат санына карап билгеләнә.
5.3. Учреждениеләрнең җитәкчеләре урынбасарлары һәм баш хисапчылары окладлары әлеге учреждение җитәкчеләренең вазыйфаи окладларыннан 20-30 процентка түбәнрәк билгеләнә.
5.4. Җитәкчеләр хезмәтенә түләү төркеме, җитәкчеләрнең окладлары күләме 5 нче таблицада күрсәтелгән.

5 нче таблица

Мәдәният учреждениеләре җитәкчеләренең окладлары

| Учреждениеләр тибы | Хезмәткә түләү буенча төркем | Аена оклад күләме - мең сум | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 |
| | Хезмәткәрләр саны, кеше | 10 га кадәр | 11 – 30 | 31 – 50 | 51 – 75 | 76 – 150 | 151 – 300 | 301 – 500 | 500 дән артык |
| Китапханә | | | 23,0 | 30,0 | 33,5 | 37,0 | 45,0 | 50,0 | |
| Клублар | | 21,0 | 27,5 | 30,0 | 33,5 | 35,0 | 40,0 | 50,0 | |
| Музейлар | | 22,5 | 26,5 | 28,0 | 35,0 | 37,0 | 45,0 | 50,0 | |
| Мәдәни-ял итү үзәге | | | 32,0 | 33,0 | 35,0 | | | | |
| Җирле радиотапшырулар | | 20,0 | | | | | | | |
| Киновидеоберләшмә | | 18,0 | 23,0 | | | | | | |
| Башкалар | | 18,0 | 33,0 | | 34,0 | 35,0 | | | |

5.5. Компенсация сыйфатындагы түләүләр учреждениеләрнең җитәкчеләре, аларның урынбасарлары һәм баш хисапчылары өчен Россия Федерациясе Хезмәт кодексы нигезендә раслана торган компенсация сыйфатындагы түләүләр төрләре исемлеге нигезендә билгеләнә.
5.6. Кызыксындыру сыйфатындагы түләүләргә учреждениенең хезмәт өчен түләү фонды чикләрендә гамәлгә куючы тарафыннан билгеләнә торган айлык премияләр

керә.

## VI. Компенсация сыйфатындагы түләүләр

6.1. Учреждениеләрдә компенсация сыйфатындагы түләүләргә түбәндәгеләр карый:
авыл җирендә эшләгән өчен белгечләргә түләү;
авыр эшләрдә, зарарлы һәм (яки) куркыныч һәм башка махсус хезмәт шартлары булган эшләрдә мәшгуль хезмәткәрләргә түләү;
нормаль (төрле квалификация эшләрен башкарганда, һөнәрләрне (вазыйфаларны) берләштергәндә, дәрестән тыш эш өчен, төнлә һәм нормаль эштән читләшкән башка шартларда эшләр башкарганда эш өчен түләү.
6.2. Компенсация сыйфатындагы түләүләр, аларны гамәлгә ашыру күләмнәре һәм шартлары хезмәт законнары һәм хезмәт хокукы нормаларын үз эченә алган башка норматив хокукый актлар нигезендә күмәк шартнамәләр, килешүләр, локаль норматив актлар белән билгеләнә.
6.3. Авыл җирлегендә эшләгән өчен белгечләргә түләүләр мәдәният хезмәткәрләренә бирелә һәм түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$B_{sm} = D_{sm} \times S,$$

биредә:

$B_{sm}$ - авыл җирлегендә эшләгән өчен белгечләргә түләү;

$D_{sm}$ - авыл җирендә эшләгән өчен белгечләргә түләү күләме 1 388,5 сум тәшкил итә;

$S$ – мәдәният хезмәткәре тарафыннан башкарыла торган ставкаларның фактагы саны.
6.4. Авыр эшләрдә, зарарлы һәм (яисә) куркыныч һәм башка махсус хезмәт шартлары белән эшләрдә мәшгуль хезмәткәрләргә компенсация сыйфатындагы түләүләр һәм нормаль (төрле квалификация эшләрен башкарганда, һөнәрләрне (вазыйфаларны) берләштергәндә, дәрестән тыш эш өчен, төнлә һәм нормаль эштән читләшкән башка шартларда эшләгәндә нормаль (төрле квалификация эшләрен башкарганда) эштән читләшкән шартларда эшләгән өчен, компенсация сыйфатындагы түләүләр түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$B_{kh} = O_d \times D_{kh} \times \frac{H_{fsd}}{H_n},$$

биредә:
$B_{kh}$ - компенсация сыйфатындагы түләүләр;
$O_d$ – мәдәният хезмәткәрләренең вазыйфаи окладлары;
$D_{kh}$ – компенсация сыйфатындагы өстәмә түләү күләме;
$H_{fsd}$ - законнар белән компенсация сыйфатындагы түләүләр карала торган чынлыкта эшләнгән вакыт;
$H_n$ – мәдәният хезмәткәрләренең хезмәт хакының төп ставкасы (төп оклады) өчен сәгать нормасы, ул Россия Федерациясе Хезмәт кодексы нигезендә кабул ителә.
6.5. Нормаль (төрле квалификация эшләрен башкарганда, һөнәрләрне

(вазыйфаларны) берләштергәндә, дәрестән тыш эш өчен, төнлә һәм нормаль эштән читләшкән башка шартларда эшләр башкарганда эш өчен түләүләр түбәндәге күләмнәрдә билгеләнә:
төнлә эшләүнең һәр сәгате нормаль шартларда эшләү белән чагыштырганда югарырак күләмдә түләнә, әмма Россия Федерациясе законнары һәм башка норматив хокукый актларында билгеләнгән күләмнән ким түгел;
